ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында” Татарстан Республикасы Законының 11 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында” 2005 елның 29 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 3; 2013, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“11 статья. **Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен матди-техник тәэмин итү**

1. Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен матди-техник тәэмин итү, коткару җайланмалары, кораллары белән җиһазландыру аларны төзегән тиешле Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре органнары, оешмалары һәм иҗтимагый берләшмәләре раслаган җиһазландыру табельләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелгән Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләрен матди-техник тәэмин итү, коткару җайланмалары, кораллары белән җиһазландыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләрен җиһазландыру табельләре нигезендә гамәлгә ашырыла.”;

2) 16 статьяда:

а) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Хезмәт шартнамәсе (контракты) белән йөкләнгән бурычларын үтәгәндә һәлак булган яисә хезмәт шартнамәсе (контракты) белән йөкләнгән бурычларын үтәгән чорда һәм шуңа бәйле рәвештә имгәнү (яралану, травма, контузия алу), авырып китү аркасында вафат булган Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләре коткаручыларының мәетләрен күчерү өчен әзерләү, күчерү, җирләүгә бәйле барлык чыгымнар, шулай ук кабер ташлары ясау һәм куюга бәйле чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары билгеләгән тәртип һәм нормалар нигезендә Татарстан Республикасы һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары бюджетлары акчалары исәбеннән тотыла.”;

б) түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

“8. Әлеге статьяның 2 һәм 5 өлешләрендә каралган чыгымнарны финанслау әлеге Законның 10 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 14 мае
№ 40-ТРЗ